МИНИСТЕРСТВО ФИНАНСОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ФИНАНС МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

18.10.2017 Казан ш. № 21-75-187

“Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында административ хокук бозулар турында беркетмәләр тутыруга һәм административ хокук бозулар турында эшләрне карап тикшерүгә һәм процессуаль документларның үрнәк формаларын тутыруга вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген раслау турында” 05.02.2015 ел, №21-75-6 Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

“Дәүләти һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен сатып алуларны хәл кылганда товарларга (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) түләү срогын һәм тәртибен бозган өчен заказчының вазыйфаи затларының административ җаваплылыгын билгеләү ягыннан административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе Кодексына үзгәрешләр кертү хакында” 26 июль, 2017 ел, №189-ФЗ Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә, боерык бирәм:

“Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында административ хокук бозулар турында беркетмәләр тутыруга һәм административ хокук бозулар турында

эшләрне карап тикшерүгә һәм процессуаль документларның үрнәк формаларын тутыруга вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген раслау турында” 05.02.2015 ел, №21-75-6 Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы боерыгына (Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 25.12.2015 ел, № 21-75-83, 19.01.2017 ел, №21-75-12 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктның 1.1 пунктчасындагы беренче абзацында “ 7.32 статьяның 1 – 6 өлешләре нигезендә,” дигән сүзләрдән соң “ 7.32.5 статьясының 1 өлеше нигезендә,” дигән сүзләр өстәргә;

2 пунктның беренче абзацында “7.32 статьясының 1 – 6 өлешләре нигезендә,” дигән сүзләрдән соң “ 7.32.5 статьясының 1 өлеше нигезендә,” дигән сүзләр өстәргә.

Министр Р.Р.Гайзатуллин